ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘКӘЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423749, Иске Теләкәй авылы,
Үзәк ур.,87 нче йорт.
Тел/факс 3-44-59

ТЛЯКЕЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423749, село Старое Тлякеево,
ул.Центральная,дом 87.
Тел/факс 3-44-59
Эл.адрес: telak-akt@yandex.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

От 07 октября 2024 г. № 10

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Теләкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Теләкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Теләкәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 20 номерлы карарына (17.07.2020 елдан 13 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 бүлекнең 3 пунктында:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - бюджетка түләүләр буенча ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бурыч өлешендә;»

б) 2_1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 һәм 5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә ярлыкау турындагы актларны штраф рәвешендә куллану яисә суд тарафыннан карар кабул итү, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән

срогы тәмамланууга бәйле рәвештә;

5) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарып биргәндә, күләме банкротлык турындагы эш буенча җитештерүне кузгату өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык узган булса, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару;

г) түбәндәге эчтәлекле 5_1 пунктчасы өстәргә:

«5_1) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча җитештерүне туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителгәндә;»

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Т.Гайнетдинов